**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-АФОНКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**МОРДВААФОНЬКӘСЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423103,Мордва Афонькәсе авылы, Цаплин урамы, 19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru

---

№ 121 20 сентябрь 2019 ел

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Җирле референдум билгеләү турында**

12.06.2002 ел, № 67 - ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22,56 статьялары, «Җирле референдум турында» 24.03.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә, Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 18 сентябрендәге № 12 номерлы “Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында " карарын карап, «Мордва Афонькәсе авыл җирлеге» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы карар **КАБУЛ ИТТЕ :**

Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә: "Мордва Афонькәсе авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү өчен түбәндәге эшләрне башкару белән килешәсезме” :

- Мордва Афонькәсе, Лагерка һәм Чуаш Афонькәсе авылларында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе өчен түләү. Югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материалларны (хезмәтләр күрсәтүне) сатып алу;

- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар(юл кырыйларын чабуга, урамнарны кардан чистартуга, кышкы вакытта кардан чистартуга), җирлек халкының өлешләп трактор һәм ротор чапкыч сатып алуга грант алуга, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга (хезмәтләр күрсәтүгә);

- Мордва Афонькәсе, торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су үткәрү башнялары урам челтәрен төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау (территориянең санитар-саклау зонасын төзекләндерү һәм су башняларын буяу) һәм югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

Лагерка авылы зираты территориясен төзекләндерү, агачлар кисү ;

- Чуаш Афонькәсе авылында автобус тукталышын(павильонын) ремонтлау;

- Мордва Афонькәсе авылы зираты һәм Лагерка авылы зиратына авыл хуҗалыгы җирләрен күчерү.

«ӘЙЕ» «ЮК »

1. Әлеге карар мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш.

Башлык, ТР Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл
җирлеге Советы рәисе А. И. Митяев